ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 17 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынына хокукын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы $2^2$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$2^2$. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору буенча, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Россия Федерациясе субъектларының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнары янәшәсендәге чик буе территорияләрендә кораллы провокация барышында бурычларны үтәгән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак урыннары белән тәэмин ителү хокукы әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән башка затларныкыннан өстен була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 30 март
№ 19-ТРЗ